**Г.Р.Гайнуллина,**
**Казан (Идел буе) федераль университеты доценты**

# Тукай турында әдәбият галиме Т.Галиуллин фикерләре

Татар халкының иң кадерле бәйрәме – Г.Тукайның туган көне якынлашкан мәлдә һәммәбез шагыйранә якты хисләр дулкынына көйләнә. Г.Тукай турындагы күпсанлы хезмәтләр яңадан барлана, эшләнәсе эшләр билгеләнеп куела.

Тукай фәне елдан-ел яңа хезмәтләр, ачышлар белән байый. Күңелендә милли хисне кадерләп саклаган һәркем үзеннән Тукай турындагы сәхифәгә өлеш кертеп калырга ашыга. Әдәбият галимнәре Г.Тукайның тормыш юлына караган яңа мәгълүматлар таба, шигърияттен үзгә якын килеп бәяли, әдәби, публицистик иҗатының киңлеген өйрәнә, Тукай фәненең торышын күздән кичерә. Әдәбият галиме, тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллин Тукай фәненең торышын бәяләп түбәндәге фикерне белдерә: “Тукай иҗатының XX гасыр татар шигъриятенә – варисларына йогынтысы әдәбият белемендә шактый тәфсилле өйрәнелгән. Хәзерге чорда бу мәсьәләнең түбәндәге якларына игътибар итү зарури: 1) иҗатына замандашлары биргән бәя; 2) совет чорының төрле дәверләрендә Тукайга мөнәсәбәтнең үзгәреп торуы; 3) Тукай мирасының хәзерге татар шигъриятенә тәэсире; 5) шигърияттә Тукай шәхесе”[1;21].

Әдипнең бөеклеген раслауны аның иҗатына замандашлары биргән бәядән башлау дөрес. “Тукайны күреп белгән яисә иҗат юлларын 1917 ел инкыйлабына чаклы башлаган М.Гафури, Ф.Бурнаш, Г.Ибраһимов, Ш.Бабич, Җ.Вәлиди кебек әдипләр остазларының иҗатын олылау юнәлешендә зур эш алып бардылар, аның мирасына тел-теш тидермәскә тырыштылар. Үзе исән чакта ук шундый дан вә абруй казанган башка затны әдәбият тарихы хәтерләми” ”[1;22].

XX йөз дәвамында әдәби мираска бәя үзгәреп, яңарып тора: “Тукайның чынбарлыкны аек бәяләвенә, тормышны бөтен муллыгында сурәтләүгә омтылган иҗат принципларына якынайган 60 нчы, 80-90 нчы елларда татар шигърияте гаярь ачышларга юлыга” ”[1;24]. Әдәбият галиме XX йөз татар поэзиясенең Тукайга бәйле зур алгарыш кичерүен раслый.

Ике гасыр чиге Тукай фәнендә яңа сәхифә – шартлы рәвештә “шигъри Тукай” дип исемләнгән юнәлеш барлыкка килү фәннең киләчәгенә юл сыза: “Тукай һәм XX гасыр татар шигърияте” дигән фәнни юнәлешне үзгәрәк югарылыкта үстерү дәвере җитте” – дип яза Т.Галиуллин [1;26]. Галимә Н.М.Гафиятуллинаның “XX гасыр татар шигъриятендә Тукай” исемле фәнни хезмәте бу юнәлештә иң матур башлангычларның берсе буларак бәяләнергә лаеклы.

“Тукайның “онытылыбрак торган”, мәктәп дәреслекләренең түрендә урын алмаган” [2;28] шигырьләрен яңадан уку – яңа гасыр Тукай фәне алдында торган алдагы бурычларның берсе.

Әдипнең мирасы җентекләп барланган дәвердә Тукай мирасына мөнәсәбәтле фикер-карашлар төрле булуы табигый: Мисалга, “... Г.Тукай белән Г.Исхакыйны капма-каршы кую кебек тайгак юлга төшүдән сак булырга кирәк. Ошбу алым әдәбиятыбызны анык, тарихи бәяләүдән читләштерер һәм кирәкмәгән, арзанлы, отышсыз бәхәсләргә кертеп бастырыр иде” [1;27]. Т.Галиуллинның “Тукайның Җаек дәверен кимсетеп, түбәнәйтеп, өйрәнчек, корама телле чор” дип бәяләүгә сак карарга кирәклеген искәртү урынлыдыр: “Тукайның өйрәнчек чоры бик тиз үтеп китә. Иркәләнеп торырга вакыт юк. “Фикер” газетасын чыгаруда катнашу, шунда наборщик, журналист, корректор булу, “Әлгасрел-җәдит” журналын нәшер итүдә булышу аның шагыйрь һәм шәхес буларак өлгерүен тизләткәндер” [3;6].

Әдипнең мирасы, шул исәптән иҗтимагый эшчәнлеге, публицистикасы шактый өйрәнелгән булса да, халкына армый-талмый хезмәт иткән бөек милләт хадиме әйтеп калдырган сүз-васыятькә үз халкының мөнәсәбәте борчый. “Әдип беренче шигырьләрен гарәп, фарсы, төрек, хәтта урыс

телләрендә дә язып калдырган. Димәк ки, ул Хафиз, Хәйям, Сәгъди, Фирдәүси әсәрләренең дә төп нөсхәләрен укый алган. Хәзерге буын язучыларыбыздан кайсыбыз шуның белән мактана ала” [3;6].

Тукай фәне даими үсештә. Тукайның 125 яшен бәйрәм итәр көннәр җитә. Тукай фәненә намуслы хезмәт итүче мөгътәбәр шәхес Т.Галиуллин сүзләренә кушылып “татар халкы аның бөеклеген XXI, XXX гасырларга илтеп җиткерергә тиеш” [1;21], дип белдерәсе килә.

Кулланылган әдәбият исемлеге:


1. Галиуллин Т.Н. Тукай һәм XX гасыр татар шигърияте // Шигърият баскычлары: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б.20-27.
2. Галиуллин Т.Н. Тукай шигырьләрен яңадан укыганда // Шигърият баскычлары: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б.28-46.
3. Галиуллин Т.Н. Тукайның Җаек чоры иҗаты – дөнья әдәбиятлары югарылыгына беренче адым // Шәхесне гасырлар тудыра: Әдәби тәнкыйть, хикәяләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. – Б.5-9.